Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 125 22 май 2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак, бушлай нигездә, коммерцияле булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турында» гы нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 16 декабрь, 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак, бушлай нигездә, коммерцияле булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2017 ел, 22 сентябрь, 45 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2018 ел, 17 декабрь, 84 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип тану турында" һәм "Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының 2017 ел, 22 сентябрь, 45 нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм башкарма орган буларак, бушлай нигездә, коммерцияле булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә

үзгәрешләркертү хакында" 2019 ел, 20 февраль, 96 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Совет рәисе,
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы: М. М. Сөләйманкин